**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге**
**Советы**

422750, Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авылы,
Совет урамы, 1
Тел,факс 884369 2-15-68

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеатнинского сельского поселения**

422750, Атнинский муниципальный район
с.Большая Атня,
ул. Советская, 1
тел, факс .884369 2-15-68

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2022 ел. № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2022 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында үзара салым кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлегенең Кече Әтнә авылында үзара салым кертү һәм файдалану турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитеты;

– халык җыенын үткәрү вакыты-2022 елның 19 ноябре, 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- уздыру урыны-Кече Әтнә авылы, Совет ур., 31Б, Кече Әтнә авыл клубы.

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итү:

- 2022 елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегендә Олы Әтнә авылы, Совет урамы, 1 нче йорт адресы буенча гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә;

- сайлау хокукы булган Кече Әтнә авылы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Кече Әтнә авылы халкына мәгълүмати стендлар һәм башка ысуллар аша халык җыены турында хәбәр итү.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яше тулган һәм тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, мобилизацияләнгән гражданнарны һәм

аларные гаилә әгъзаларын һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү буенча түбәндәге эшләрне башкару:

1) Кече Әтнә авылының Совет, К. Маркс һәм Тукай урамнарын төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар ,куаклар, үсентеләр кисү, каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр алып китү);

2) Совет урамындагы Кече Әтнә авылы торак пунктының урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, капламаларны ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү);

3) Спорт мәйданчыгы төзү;

«КАРШЫ»

«РИЗА»

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://atnya.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Кече Әтнә авылы, К.Маркс ур., 1 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең административ бинасында урнашкан Олы Әтнә Советская урамындагы мәгълүмат стендында.

4. Әлеге карар аны игълан иткән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы: Г.Г.Хакимов